КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 июль г.Казань № 596

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру турында» 2014 ел, 6 февраль, 65 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру турында» 2014 ел, 6 февраль, 65 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 24 ноябрь, 903 нче, 2023 ел, 15 май, 593 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 һәм 3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән республика башкарма хакимият органнары тәкъдимнәре буенча гражданнар оборонасы максатларында запаслар номенклатурасы һәм күләмнәре Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министры урынбасарының 2021 елның 29 декабрендәге 2-4-71-11 номерлы тарафыннан расланган Федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар туплаган матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын гражданнар оборонасы максатларында төзелә торган номенклатураны һәм күләмнәрен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне исәпкә алып Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана;

гражданнар оборонасы максатларында запаслар булдыру Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш

хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла;

гражданнар оборонасы максатларында запаслар булдыру буенча оештыру-методик җитәкчелек итүне Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә;

гражданнар оборонасы максатларында запаслар булдыру һәм аларның тоту чыгымнарын финанслауны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырырга.

3. Җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы оешмалары җитәкчеләренә вәкаләтләр чикләрендә гражданнар оборонасы максатларында запаслар булдыруны тәэмин итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы максатларында матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын (алга таба – запаслар) булдыруны тәэмин итүче башкарма хакимиятнең республика органнары исемлегендә:

2 пунктның 3 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дару препаратлары, медицина эшләнмәләре»;

3 пунктның 3 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Химик яклау һәм разведка чаралары»;

4 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин